# Хокукый акт проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү

Әлеге мәгълүмат белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» боерыгы проекты буенча (алга таба – проект), атап әйткәндә, 16:08:150202:530 кадастр номерлы, 1001 кв. м мәйданлы Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Каратун авыл җирлеге, Морзалар авылы, Северная урамы адресы буенча урнашкан җир кишәрлегеннән файдалануның Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Каратун авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1.3) «автомобильләр ремонтлау» шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында гавами тыңлаулар башлануы хакында хәбәр итәбез.

**Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

1)фото 1-Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Каратун авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән Өземтә 16.10.2023 №149;
2)фото 2-индивидуаль торак төзелеше зонасы Ж1. 3
3)таблица-җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм капиталь төзелеш объектларын төзүнең һәм реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрлары;
4)фото 3-ЗОУИТ;
5) фото 4 - Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Каратун авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планыннан.

**Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча ачык тыңлаулар 2025 елның 24 октябреннән 2025 елның 7 ноябренә кадәр уздырыла.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект әзерләнгән җир кишәрлеге урнашкан чикләрендә даими яшәүче гражданнар;
шушы территориаль зона чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
проект әзерләнгән җир кишәрлегенә якын җир кишәрлекләре чикләрендә даими яшәүче гражданнар;
мондый җир кишәрлекләренең яисә аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
проект әзерләнгән капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре;
мондый тискәре йогынты куркынычы янаган җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, –

җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төре әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясарга мөмкин булган очракта.

**Проект әзерләнгән Территория:**
кадастр номеры 16:08:150202:530, мәйданы 1001 кв. м булган җир кишәрлеге, адресы**:** Татарстан Республикасы, Апас муниципаль районы, Каратун авыл җирлеге, Морзалар авылы, Северная ур.

**Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен (экспозицияләрен) ачу урыны һәм датасы:**
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: Татарстан Республикасы, Апас районы, Морзалар авылы, Татарстан ур., 18 йорт – 24 октябрь 2025 ел.

**Проект экспозициясен (экспозицияләрен) үткәрү сроклары:**
2025 елның 24 октябреннән 2025 елның 7 ноябренә кадәр.

**Экспозицияне (экспозицияләрне)карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**
Эш көннәрендә 9.00 дән 16.00 гә кадәр, төшке аш тәнәфесе-12.00 дән 13.00 гә кадәр

**Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

2025 елның 24 октябреннән 2025 елның 7 ноябренә кадәрге чорда РФ Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГрК) 5 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышында яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән;

2) язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлауларны оештыручыга-422350 адресы буенча Оештыру комитетына, Татарстан Республикасы, Апас районы, Апас штп, Совет ур., 2 йорт (гавами тыңлаулар буенча оештыру комитеты) яисә электрон почта адресы буенча apast@tatar.ru;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язып кую юлы белән.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын (җыелышларын) үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

2025 елның 8 ноябрендә Мәскәү вакыты белән 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Апас районы, Морзалар ав., Татарстан ур., 18 йорт.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат, һәм аңа мәгълүмати материаллар: Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтына сылтама-https://apastovo.tatarstan.ru " район турында /авыл җирлекләре /Каратун авыл җирлеге/гавами тыңлаулар.

**Әлеге хәбәрнамәне** Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары — А.М. Хәсәнов

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече — А.В. Нурмиева

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге башлыгы, дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы депутатлар Советы депутаты — Р.С. Исмәгыйлев

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы — Э.Ф. Шакирова

Апас муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе — Г.М. Сибгәтуллина